

Козге ярмарка сентябрь башында үтте инде. Бездә алар еш була. Халык аннан арзан бәягә ашамлыклар алганга, анда халык яратып йори. 28нче октябрьдә Саранск шәһәренен һәрбер районында, Олкәннәр аена да туры китерелгән авыл хуҗалыгы ярминкәсе булып үтте. Ярмарка киштәләрендә нигездә күбрәк җәй конендә үстерелгән байлыклар урын алган иде.

Сатуда 190 сум/кг - сыер ите (дунгызныкы - 165), кош ите – тавык - 85 сум/кг, күркә - 170), сарык ите 300 сумнан килограммы, каты сортлы сыр- 290 сум/кг, мәсәлән, «Пармезан» или «Чеддер» бәярәк булса да халык яратып күп иттереп алдылар. Ә йомырка турында әйтәсе дә юк, утыз сумнан дистәсен халык рәхәтләнеп алды, чираты да юк диярлек. Рафинировать ителгән конбагыш мае 55 сумнан литры һәм шикәр комы 29 сум килограммы. Шулай ук он, корпә, яшелчә, балык, консервлар, эчемлекләр, кондитер һәм макарон продукциясе һәм башка тор ашамлыклар сатылды. «Татлытамаклар» очен куертылган сот, бал да сатып алырга була иде. Эшкәртү предприятияләре продукциясеннән башка, сатып алучыларны шулай ук авыл жирлекләреннән алып килеп корган палаткалар да жәлеп итте.

Ярминкәдә урманнарда һәм посадкалардан жыелган гомбәләрне дә сатып алырга була иде. Яшелчәләргә килгәндә, кәбестә - 8 сум/кг, бәрәнге - 12 сум/кг, чогендер - 13 сум/кг, суган һәм кишер - 15әр сум/кг... Ләмберә, Старошайгово, Рузаевка районнарыннан килгән эшмәкәрләр жи-меш агачлары, куаклар, чәчәк үсентеләре белән дә сату иттеләр. Арзангарак сатып аласы, кыйммәтрәк сатасы - ярминкәдә бу аксиома әһә-миятле түгел иде. Күрәмсен, яр-минкә - ул базар түгел, сатулашу урынсыз, дип уйлаганнардыр сатучылар һәм шуна да алар бәяләрне алдан үк килешеп куйганнар, алай гына да түгел, үзләренен сатып алучыларын, кадерле кунаклар кебек, сыйладылар да.

- Ромодан районы сатучыларыннан мин шикәр комы сатып алдым. Ә яшелчәләрнен югары сыйфатлыларын «Тепличный»дан (берничә машинада) сатарга алып чыкканнар; кишерләре белән суганнарын алдым. Кешеләр килеп чиратта тормый гына кирәк ашамлыкларын алып китә бардылар, шул ягы сатып алучылар очен бик тә унай булды, - дип сойләде Рахилә Әминулла кызы Исмаилова. - Күнелгә хуш килгәннәренен тагы бер ягы – волонтерлар олыларга алган әйберләрен «Газель»ләргә кадәр күтәреп алып барырга ярдәм иттеләр, ә «Газель»ләр түләүсез шәһәрнен һәрбер районына кадәр илтеп тә куя бардылар, - диде ул.

- Әйе, ярмарка бик күнелле, яхшы узды, ул шулай булырга тиеш тә, - дип сүзгә кушылды пенсия яшендәге күрше хатыны Александра Егор кызы Евсеева. - Бернәрсә дә сатып алмасан да, чыгып жырлар, такмаклар тынлыйсын, танышлар белән очрашып

сойләшәсен. Ярмаркачылар очен чәй-кофе, шашлык белән сыйланып алырга да момкинчелекләр тудырылган иде. Шулай Саранскта тагы бер ярморка үтте.

**Н.Хәлил**